

Сентябрь ае башында Кочкурово районы Подлесная Тавла авылында «Тавла аты» дигән Регионара агач уеп бизәү фестивале узды. Ел саен үткәрелә торган фестиваль, гадәттәгечә, осталарны Мордовиядән генә түгел, Россиянен башка олкәләреннән дә жыйды.
«Тавла аты» тобәкара агач кисүчеләр фестивален уздыру Президентнын Мәдәни инициативалар фонды гранты ярдәме бе-лән момкин булды. Чара музыкант, фольк-лорчы, этнограф, «Торама» торкемен оештыручы Владимир Иванович Ромашкиннын туган конендә музей-йорт территориясендә узды.
Дүрт кон эчендә «Этно-кудо» музее территориясендә торле тобәкләрдән кил-гән осталар бергәләп Тавла аты скульп-турасын ясадылар: Гиннес рекордлар китабына лаеклы парк скульптурасы булдырылды. Нәтижә бик тәэсирле булды: биеклеге 4,5 метр һәм озынлыгы 6,5 метр агач скульптура барлыкка килде. Кыскасы, ике этажлы йорт кадәр. Шулай ук «Этно-Кудо» музеенда борынгы әрзә жырынын сигезенче «Зов Торама» фестиваленә йомгак та ясалды. Фестивальнен кульминациясе- чылбырлы тизйорешле шоу һәм бәйрәм символы - Тавла аты тирәсендә зур әйлән-бәйлән булды.
Әйтеп китәргә кирәк, борынгы заманнардан ук ат, кешенен тугры юлдашы. Ана барлык халыклар, шул исәптән мордвалар да илаһи булган. XIX-XX гасырларнын борынгы мордва каберлекләреннән археологик табылдыклар арасында даими рәвештә ат сурәте тошерелгән бронза зәркән (ювелир) бизәнү әйберләре очрый. Сонгы чорларда һәм бүгенге конгә кадәр атнын стилизацияләнгән образлары торак биналар һәм савыт-саба әйберләре декорынын аерылгысыз олеше.
Мордовиянен Кочкурово районы Подлесная Тавла авылы осталары ижатында ат топ персонажларнын берсе булып тора. Осталар ясаган үзенчәлекле, агачтан киселгән кешеләр һәм хайваннар фигуралары күптәннән Россиядә генә түгел, күп кенә илләрдә дә популяр. Тавла традицион сәнгате бик күп талантлы осталар үстерде. Алар арасында абыйлы-энеле Рябовлар - Петр, Николай һәм Александр да бар; аларнын һәркайсы ижатта тормышка ашып кына калмыйча, үзләренен сәнгать стилен таба алган. Бу аеруча кадерле. Алар осталык серләрен башкалар белән уртаклашалар. Остәвенә, олкән Пётрлары сәнгать һонәрен популярлаштыру омтылышында житештерел-гән эшләрне күрсәтү белән генә канәгать булмый. Ул бик теләп Мордовиядә һәм илнен башка тобәкләрендә, чит илдә мастер-класс-лар үткәрә. Россиянен һәм якын чит илләрнен торле почмакларыннан килгән талантлы коллегаларын туган Подлесный Тавласы басуында резчыклар фестивальләрен бик теләп оештыра.
«Тавла осталары союзы» ижтимагый оешмасы рәисе, Россия рәссамнар Берлеге әгъзасы, Россиянен ха- лык остасы Петр Владимирович Рябов кырык елдан артык агач

уеп ясау олкәсендә халык традицияләренен ин тугры һәм эзлекле дәвамчысы. Рәссам, борынгы осталар кебек, бер vк персонажларнын образларын vзгәртә, алар арасында кеше белән бергә ат. Торле зурлыктагы ат сыннары: канатлы «Пегаслар», ат рәвешендәге тәгәрмәчле балалар уенчыклары, чаначык-лары һәм сыбызгылары кvп. Петр Рябовнын ижат эшчәнлеге дәве-рендә ул ботен доньяда таныла торган vзенен «Тавла стилен» - Мордовиянен ин топ, якты милли сувенирында ат образын характерлый торган сыйфатлар тудыра һәм эшли.

**Наилә НАСЫРОВА**